Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Иске Кощаково авылы
Нагорный урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

12 ноябрь, 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Иске Кощаково авылы Нагорный урамы гражданнары җыенының 2023 елның 12 ноябрендәге протоколы нигезендә карар кабул ителде:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Кощаково авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар җыены: «2024 елда Кощаково авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы Тау урамында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен юллау белән килешәсезме:

- балалар мәйданчыгы төзү» **узмаган дип санарга кирәк**.

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова